| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2023 г. Казань № 854-140/кс-2023

2024 елга Биектау муниципаль районы «Биектау коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2023 №60-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы Биектау муниципаль районы «Биектау коммуналь челтәрләре» акционерлык җәмгыяте (алга таба – «Биектау коммуналь челтәрләре» АҖ) өчен, әлеге карар кушымтасы нигезендә, календарь буенча бүлеп, эчә торган суга, техник суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Биектау коммуналь челтәрләре» АҖ иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу

өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2023 № 854-140/кс-2023
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы
«Биектау коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2024 елга эчә торган суга,
техник суга һәм ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 01.01.202 4 башлап 30.06.202 4 кадәр | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр |
| | Биектау муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Биектау коммуналь челтәрләре» АҖ, технологик яктан үзара бәйләнмәгән үзәкләштерелгән берничә система булуына карап, тарифларны дифференциацияләү: | | | | | | |
| 1.1 | Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре кулланучылары | | | | | | |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 26,04 | 30,86 | | | 31,12 | 37,28 |
| 1.1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 21,70 | 25,72 | | | 25,93 | 31,07 |
| 1.2 | Дачный авыл җирлеге кулланучылары | | | | | | |
| 1.2.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 35,16 | 44,63 | | | 38,81 | 46,57 |
| 1.2.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 29,30 | 37,19 | | | 32,34 | 38,81 |
| 1.3 | Чернышевка авыл җирлеге кулланучылары | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1.3.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 39,31 | 48,73 | | | 57,54 | 66,78 |
| 1.3.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 32,76 | 40,61 | | | 47,95 | 55,65 |
| 1.4 | Алан-Бәксәр, Каенлык, Олы Битаман, Олы Кавал, Казаклар, Алат, Суыксу авыл җирлекләре кулланучылары | | | | | | |
| 1.4.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 39,31 | 48,73 | | | | |
| 1.4.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 32,76 | 40,61 | | | | |
| 1.5 | Бөреле, Иске Казан, Ташлы Ковал, Чыпчык авыл җирлекләре кулланучылары | | | | | | |
| 1.5.1 | халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | 27,45 | 30,86 | | | | |
| 1.5.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 22,88 | 25,72 | | | | |
| 1.6 | Бөреле авыл җирлеге кулланучылары | | | | | | |
| 1.6.1 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелә)* | | | | | 43,40 | 48,42 |
| 1.6.2 | Башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | | | | | 36,17 | 40,35 |
| 1.7 | Дөбъяз, Семиозерка һәм Усад авыл җирлекләре кулланучылары (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | | | 28,47 | 28,47 | | |
| 1.8 | Биектау авыл җирлеге кулланучылары (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | | | 25,34 | 25,34 | | |

* Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын үтәү максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге